РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«21» март 2025г. г. Альметьевск №349

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә хакында» 2018 елның 31 маендагы 244 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә хакында» 2018 елның 31 маендагы 244 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 16 декабрендәге 343 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 40 номерлы, 2021 елның 17 июнендәге 58 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 144 номерлы, 2023 елның 29 мартындагы 212 номерлы, 2023 елның 6 декабрендәге 264 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның «Район башкарма комитеты вәкаләтләре» 2 бүлегендә:

1.1.1. 2.2 пунктның 3 пунктчасының җиденче абзацында «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү;» сүзләрен өстәргә;

1.1.2. 2.2 пунктның 7 пунктчасына өченче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- муниципаль мәгариф оешмаларында спортка әзерлекнең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыра;»;

1.1.3. 2.2 пунктның 8 пунктчасындагы унынчы абзацта «, шулай ук рекреация максатларында су объектларыннан файдалану кагыйдәләре» сүзләрен өстәргә.;»;

1.1.4. 2.3 пунктның бишенче абзацында «федераль законнар белән» сүзләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында

«2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләренә алмаштырырга;»;

1.2. карарга 1 нче кушымтаның «район Башкарма комитет җитәкчесе» 3 бүлегендә:

1.2.1. 3.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.4.1 пунктчасы өстәргә:

«3.4.1. Район Башкарма комитеты җитәкчесе «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы тору максатларында башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы көрәш турында»2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылса. »;

1.2.2. 3.10.2 пунктта «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.1.1 пунктчасы нигезләмәсенең гамәлдә булуы 2024 елның 01 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.1.2 пунктчасы нигезләмәсенең гамәлдә булуы 2023 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә. (Туманова Г.П.).

Муниципаль район башлыгы вазыйфаларын башкаручы — Р.Е. Әфләтунова

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»